**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТУЙМЕТКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИВАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Үзек урамы, 39 йорт, Ивашкино авылы, 423113

ул.Центральная, д.39, с.Ивашкино, 43113
тел./фак (84396) 3-82-19 email: Iva.Cmn2@tatar.ru

**№ 26** **21 октябрь 2025 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» № 17 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясындагы 3.2 пунктының дүртенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:
1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» № 17 карары белән (Туймәт авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 21 сентябрендәге 22 номерлы карары, 2022 елның 12 декабрендәге 22 номерлы, 2023 елның 12 декабрендәге 22 номерлы, 2024 елның 05 декабрендәге 10 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Туймәт авыл җирлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә, 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чирмешән

муниципаль районының Туймәт авыл җирлеге бюджетыннан башланган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге караның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.В. Мортазин

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2025 елның 21 октябрендәге № 26
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Туймәт авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге**

| Бюджет классификациясе коды | | Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторы исеме/ Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге бюджеты керемнәренең төре (ярдәмче төре) коды исеме |
|---|---|---|
| керемнәрнең баш администраторының | Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге бюджеты керемнәренең төрләре (төркемчәләре) | |
| 1 | 2 | 3 |
| **Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы** | | |
| 165 | 1 11 05025 10 0000 120 | Аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук авыл җирлекләре милкендәге җирләрне арендалау шартнамәләрен төзү хокукын сатудан кергән акчалар (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләрнең җир кишәрлекләреннән тыш) |
| 165 | 1 11 05026 10 0000 120 | Авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар буенча идарә итү һәм эш итү буенча вәкаләтләр Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә алына торган керемнәр, шулай ук күрсәтелгән җир кишәрлекләрен арендалау килешмәләрен төзү хокукын сатудан кергән акчалар |
| 165 | 1 11 05035 10 0000 120 | Авыл җирлекләре белән идарә итү органнарының һәм алар төзегән учреждениеләрнең оператив идарәсендә һәм муниципаль унитар предприятиеләрнең хуҗалык карамагындагы милекне арендага бирүдән кергән |

| | | |
|---|---|---|
| | | табыш (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) |
| 165 | 1 11 09045 10 0000 120 | Авыл җирлекләре милкендәге милекне файдаланудан башка төрле керемнәр (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр милкеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр милкеннән тыш, шул исәптән казна) |
| 165 | 1 13 02065 10 0000 130 | Авыл җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә керә торган керемнәр |
| 165 | 1 13 01995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджеты акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр (эшләр) күрсәтүдән башка керемнәр |
| 165 | 1 13 02995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр |
| 165 | 1 14 01050 10 0000 410 | Авыл җирлекләре милкендәге фатирларны сатудан кергән табыш. |
| 165 | 1 14 02052 10 0000 410 | Авыл җирлекләре белән идарә итү органнары карамагындагы учреждениеләр (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) оператив идарәсендәге мөлкәтне сатудан керемнәр, әлеге мөлкәт буенча төп чараларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 165 | 1 14 02052 10 0000 440 | Авыл җирлекләре белән идарә итү органнары карамагындагы учреждениеләр оператив идарәсендәге мөлкәтне (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән тыш) сатудан керемнәр, әлеге мөлкәт буенча матди запасларны сату өлешендә |
| 165 | 1 14 02053 10 0000 410 | Авыл җирлекләре милкендәге бүтән мөлкәтне сатудан керемнәр (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш), күрсәтелгән мөлкәт буенча төп чараларны гамәлгә ашыру өлешендә |
| 165 | 1 14 02053 10 0000 440 | Авыл җирлекләре милкендәге бүтән мөлкәтне сатудан керемнәр (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш), әлеге мөлкәт буенча матди запасларны сату өлешендә |
| 165 | 1 14 06025 10 0000 430 | Авыл җирлекләре милкендәге җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр (муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләрнең җир кишәрлекләреннән тыш.) |
| 165 | 1 16 10032 10 0000 140 | Авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә (муниципаль бюджет (автоном) учреждениеләренә, унитар предприятиеләргә беркетелгән мөлкәттән тыш) |

| | | |
|---|---|---|
| | | китерелгән зыянны башка төрле каплау |
| 165 | 1 17 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган түләүләр |
| 165 | 1 17 02020 10 0000 180 | Авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан авыл хуҗалыгы җирләрен тартып алу белән бәйле авыл хуҗалыгы җитештерүе югалтуларын каплау (2008 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән йөкләмәләр буенча) |
| | **Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе** | |
| 182 | 1 01 02010 01 0000 110 | Россия Федерациясе Салым кодексының 227, 227.1 һәм 228 статьялары нигезендә салым исәпләү һәм түләү башкарыла торган керемнәрдән тыш, чыганагы салым агенты булган керемнәрдән физик затлар керемнәренә салым, шулай ук оешмада өлешләп катнашудан физик зат - Россия Федерациясе Салым резиденты тарафыннан дивидендлар рәвешендә алынган керемнәр (2025 елның 1 гыйнварына кадәрге салым чорларында 650 мең сумнан артмаган салым суммасы өлешендә, шулай ук 2025 елның 1 гыйнварыннан соң салым чорларында 312 мең сумнан артмаган салым суммасы өлешендә), шулай ук физик затларның керемнәренә салым Россия Федерациясенең салым резиденты булмаган физик зат тарафыннан алынган оешмада дивидендлар рәвешендә өлешләп катнашу |
| 182 | 1 01 02020 01 0000 110 | Россия Федерациясе Салым кодексының 227 статьясы нигезендә индивидуаль эшкуарлар, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариуслар, адвокат кабинетларын гамәлгә куйган адвокатлар һәм хосусый практика белән шөгыльләнүче башка затлар буларак теркәлгән физик затлар тарафыннан эшчәнлек алып барудан алынган керемнәрдән физик затлар керемнәренә салым (2025 елның 1 гыйнварына кадәрге салым чорлары өчен салым суммасының 650 мең сумнан артмаган өлешендә, шулай ук 2025 елның 1 гыйнварыннан соң салым чорлары өчен 312 мең сумнан артмаган салым суммасы өлешендә) |
| 182 | 1 01 02021 01 0000 110 | Россия Федерациясе Салым кодексының 227 статьясы нигезендә индивидуаль эшкуарлар, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариуслар, адвокат кабинетларын гамәлгә куйган адвокатлар һәм хосусый практика белән шөгыльләнүче башка затлар буларак теркәлгән физик затлар тарафыннан эшчәнлек алып барудан алынган керемнәрдән физик затлар керемнәренә салым (салым базасының 2,4 миллион |

| | | |
|---|---|---|
| | | сумнан артып киткән һәм 5 миллион сумнан артмаган өлешенә карый торган 312 мең сумнан артык салым суммасы өлешендә), |
| 182 | 1 01 02030 01 0000 110 | Россия Федерациясе Салым кодексының 228 статьясы нигезендә физик затлар тарафыннан алынган керемнәрдән физик затлар керемнәренә салым (оешмада өлешчә катнашудан Россия Федерациясе Салым резиденты тарафыннан дивидендлар рәвешендә алынган керемнәрдән тыш) (2025 елның 1 гыйнварына кадәр салым чорларында 650 мең сумнан артмаган салым суммасы өлешендә, шулай ук салым суммасының 2025 елның 1 гыйнварыннан соң салым чорлары өчен 312 мең сумнан артмаган өлешендә) |
| 182 | 1 01 02040 01 0000 110 | Россия Федерациясе Салым кодексының 227.1 статьясы нигезендә патент нигезендә найм буенча хезмәт эшчәнлеген башкаручы чит ил гражданнары булып торучы физик затлар тарафыннан алынган керемнәрдән фиксацияләнгән аванс түләүләре рәвешендәге физик затлар керемнәренә салым |
| 182 | 1 01 02050 01 0000 110 | Салым органына тиешле хәбәрнамә бирү нигезендә махсус тәртипкә күчүгә бәйле рәвештә түләнә торган түләүдән тыш, әлеге компаниянең контрольдә тотучы затлары дип танылган физик затлар тарафыннан алынган контрольдә тотыла торган чит ил компаниясе табышы суммаларыннан физик затлар керемнәренә салым (2025 елның 1 гыйнварына кадәр салым чорларында 650 мең сумнан артмаган салым суммасы өлешендә, шулай ук 2025 елның 1 гыйнварыннан соң салым чорлары өчен 312 мең сумнан артмаган салым суммасы өлешендә) |
| 182 | 1 01 02060 01 0000 110 | Россия Федерациясе территориясендәге банкларда кертемнәр (счетлардагы калдыклар) буенча алынган процентлар рәвешендәге керемнәргә карата физик затлар керемнәренә салым |
| 182 | 1 01 02070 01 0000 110 | Россия оешмаларының сумнарда номинацияләнгән һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан соң эмитацияләнгән әйләнештәге облигацияләре буенча алына торган процент (купон, дисконт) рәвешендәге керемнәргә карата, шулай ук элеккеге СССРның, Союздаш дәүләтнең катнашучы дәүләтләренең дәүләт казначылык йөкләмәләре, облигацияләре һәм башка дәүләт кыйммәтле кәгазьләре буенча процентлар суммасы рәвешендәге керемнәргә карата физик затлар |

| | | |
|---|---|---|
| | | керемнәренә салым |
| 182 | 1 01 02080 01 0000 110 | Салым базасының 5 миллион сумнан артык өлешенә караган 650 мең сумнан артык салым суммасы өлешендә физик затлар керемнәренә салым (контрольдә тотыла торган чит ил компаниясе табышы суммаларыннан физик затлар керемнәренә салымнан, шул исәптән контрольдә тотыла торган чит ил компаниясенең фиксацияләнгән табышыннан, шулай ук оешмада өлешләп катнашудан алынган керемнәргә карата физик затлар - Россия Федерациясенең салым резиденты тарафыннан дивидендлар рәвешендә керемнәренә салымнан тыш) - 2025 елның 1 гыйнварына кадәрге салым чорлары өчен, шулай ук салым базасының 2,4 миллион сумнан артып киткән һәм 5 миллион сумнан артмаган өлешенә караган 312 мең сумнан артыграк салым суммасы өлешендә физик затлар керемнәренә салым (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 50 статьяның утыз тугызынчы абзацында күрсәтелгән керемнәргә карата физик затлар керемнәренә салымнан тыш, 2,4 миллион сумнан арткан Россия Федерациясе Салым кодексының 210 статьясының 6 пунктында күрсәтелгән салым базалары суммасына караган 312 мең сумнан артыграк өлешендә физик затлар керемнәренә салым (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 50 статьясындагы утыз бишенче һәм утыз алтынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәргә карата физик затлар керемнәренә салымнан тыш), шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 224 статьясындагы 3 пунктының тугызынчы абзацында күрсәтелгән Россия Федерациясенең салым резиденты булмаган физик затлар керемнәренә карата 2,4 миллион сумнан артык салым базасы өлешенә караган 312 мең сумнан артыграк салым суммасы өлешендә салым) 2025 елның 1 гыйнварыннан соң салым чорлары өчен |
| 182 | 1 01 02090 01 0000 110 | Салым органына тиешле хәбәрнамә бирү нигезендә түләүнең махсус тәртибенә күчкән әлеге компаниянең контрольдә тотучы затлары дип танылган физик затлар тарафыннан алынган контрольдә тотыла торган чит ил компаниясе табышы суммаларыннан физик затлар керемнәренә салым (2025 елның 1 гыйнварына кадәр салым чорларында 650 мең сумнан артмаган салым суммасы өлешендә, шулай ук 2025 елның 1 гыйнварыннан соң салым чорлары өчен 312 мең |

| | | |
|---|---|---|
| | | сумнан артмаган салым суммасы өлешендә) |
| 182 | 1 01 02100 01 0000 110 | Салым органына тиешле хәбәрнамә бирү нигезендә махсус тәртипкә күчүгә бәйле рәвештә түләнә торган түләүдән тыш, әлеге компаниянең контрольдә тотучы затлары дип танылган физик затлар тарафыннан алынган контрольдә тотыла торган чит ил компаниясе табышы суммаларыннан физик затлар керемнәренә салым (2025 елның 1 гыйнварына кадәр салым чорларына 650 мең сумнан артыграк салым суммасы өлешендә, шулай ук 2025 елның 1 гыйнварыннан соң салым чорына 312 мең сумнан артык, әмма 702 мең сумнан артык булмаган салым суммасы өлешендә) |
| 182 | 1 01 02110 01 0000 110 | Салым органына тиешле хәбәрнамә бирү нигезендә түләүнең махсус тәртибенә күчкән әлеге компаниянең контрольдә тотучы затлары дип танылган физик затлар тарафыннан алынган контрольдә тотыла торган чит ил компаниясе табышы суммаларыннан физик затлар керемнәренә салым (2025 елның 1 гыйнварына кадәр салым чорына 650 мең сумнан артык салым суммасы өлешендә, шулай ук 312 мең сумнан артык салым суммасы өлешендә, әмма 2025 елның 1 гыйнварыннан соң салым чорлары өчен 702 мең сумнан артык түгел) |
| 182 | 1 01 02120 01 0000 110 | Физик затлар керемнәренә салым Россия Федерациясе Салым кодексының 228 статьясындагы 6 пунктының сигезенче абзацында каралган шарт үтәлгән салым түләүчеләр тарафыннан салым хәбәрнамәсе нигезендә түләнә торган салым базасының 2,4 миллион сумнан артыграк өлешенә караган салым суммасы өлешендә |
| 182 | 1 01 02130 01 0000 110 | Физик зат - Россия Федерациясе Салым резиденты тарафыннан оешмада өлешчә катнашудан дивидендлар рәвешендә алынган керемнәргә карата физик затлар керемнәренә салым (2025 елның 1 гыйнварына кадәрге салым чорларында 650 мең сумнан артмаган салым суммасы өлешендә, шулай ук 2025 елның 1 гыйнварыннан соң салым чорларында 312 мең сумнан артмаган салым суммасы өлешендә) |
| 182 | 1 01 02140 01 0000 110 | Физик зат - Россия Федерациясе Салым резиденты тарафыннан оешмада өлешчә катнашудан дивидендлар рәвешендә алынган керемнәргә карата физик затлар керемнәренә салым (2025 елның 1 гыйнварына кадәрге салым чорларына 650 мең сумнан артыграк салым суммасы өлешендә, шулай ук 2025 елның 1 гыйнварыннан соң салым чорларына 312 мең сумнан артыграк салым суммасы өлешендә) |
| 182 | 1 01 02210 01 0000 | Физик затлар керемнәренә салым Россия Федерациясе |

| | | |
|---|---|---|
| | 110 | Салым кодексының 210 статьясының 6.2 пунктында күрсәтелгән салым базасына караган салым суммасының 5 миллион сумнан артмаган өлешендә |
| 182 | 1 05 03010 01 0000 110 | Бердәм авыл хуҗалыгы салымы |
| 182 | 1 06 01030 10 0000 110 | Авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан салым салу объектларына кулланыла торган ставкалар буенча физик затлар мөлкәтенә салым |
| 182 | 1 06 06033 10 0000 110 | Авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенә ия булган оешмалардан җир салымы |
| 182 | 1 06 06043 10 0000 110 | Авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенә ия физик затлардан җир салымы |
| 182 | 1 09 04053 10 0000 110 | Авыл җирлекләре территорияләрендә туплана торган җир салымы (2006 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән йөкләмәләр буенча) |
| **Чирмешән муниципаль районының финанс-бюджет палатасы** | | |
| 500 | 1 08 04020 01 0000 110 | Россия Федерациясе закон актлары нигезендә нотариаль гамәлләр башкаруда вәкаләтле җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы |
| 500 | 1 08 07175 01 0000 110 | Җирлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан куркыныч, авыр һәм (яки) зур габаритлы йөк ташучы транспорт чараларының автомобиль юллары буенча хәрәкәт итүгә махсус рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы, ул авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә |
| 500 | 1 13 01995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр (эшләр) күрсәтүдән башка керемнәр |
| 500 | 1 13 02065 10 0000 130 | Авыл җирлекләре мөлкәтен эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны каплау тәртибендә керә торган керемнәр |
| 500 | 1 13 02995 10 0000 130 | Авыл җирлекләре бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр |
| 500 | 1 16 10031 10 0000 140 | Авыл җирлеге бюджеты акчаларын алучылар файда алучы булып торганда, иминият очраклары килеп чыкканда зыянны каплау |
| 500 | 1 16 10061 10 0000 140 | Авыл җирлеге муниципаль органы (муниципаль казна учреждениесе) белән муниципаль контракт төзүдән баш тартудан килгән зыяннарны, шулай ук дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен (муниципаль юл фонды акчалары исәбеннән финанслана торган муниципаль контракттан тыш) авыл җирлеге бюджетына |

| | | |
|---|---|---|
| | | күчерелергә тиешле башка акчаларны каплау максатларында түләүләр |
| 500 | 1 16 10100 10 0000 140 | Бюджет акчаларын законсыз яки максатсыз куллану нәтиҗәсендә (авыл җирлекләре бюджетлары өлешендә) китерелгән зыянны каплауга салына торган акчалата түләүләр |
| 500 | 1 16 10123 01 0000 140 | 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычны түләү счетына кергән, 2019 елда гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиешле акчалата түләтүдән (штрафлардан) керемнәр |
| 500 | 1 16 02020 02 0000 140 | Муниципаль хокукый актларны бозган өчен административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән административ штрафлар |
| 500 | 1 16 07090 10 0000 140 | Авыл җирлеге муниципаль органы (муниципаль казна учреждениесе) каршында йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта закон яисә шартнамә нигезендә түләнгән бүтән штрафлар, неустойкалар, пенялар |
| 500 | 1 17 01050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган түләүләр |
| 500 | 1 17 05050 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларының салымга карамаган башка керемнәре |
| 500 | 1 17 14030 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына күчерелә торган гражданнарның үзара салым акчалары |
| 500 | 1 17 16000 10 0000 180 | Авыл җирлегенең бердәм бюджет счетына күчерелгәннән соң өч елдан да соңга калмыйча кире кайтару (төгәлләү) башкарылмаган ачыкланмаган керемнәр өлешендә авыл җирлекләре бюджетларының башка салым булмаган керемнәре |
| 500 | 2 02 15001 10 0000 150 | Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр |
| 500 | 2 02 15002 10 0000 150 | Бюджетларның баланслылыгын тәэмин итү чараларын хуплап авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр |
| 500 | 2 02 16001 10 0000 150 | Муниципаль районнар бюджетыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр |
| 500 | 2 02 25519 10 0000 150 | Мәдәният тармагына ярдәм итү өчен авыл җирлекләре бюджетларына субсидия |
| 500 | 2 02 29900 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына җирле бюджетлардан субсидияләр |

| | | |
|---|---|---|
| 500 | 2 02 29999 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына башка субсидияләр |
| 500 | 2 02 35118 10 0000 150 | Җирлекләрнең, муниципаль һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр |
| 500 | 202 40014 10 0000 150 | Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларыннан авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар |
| 500 | 2 02 49999 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар |
| 500 | 2 04 05020 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетлары акчаларын алучыларга дәүләтнеке булмаган оешмалар тарафыннан бирелә торган акчалата иганәдән керемнәр |
| 500 | 2 04 05099 10 0000 150 | Дәүләтнеке булмаган оешмалардан авыл җирлекләре бюджетларына башка түләүсез керемнәр |
| 500 | 2 07 05030 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына башка төрле түләүсез керемнәр. |
| 500 | 208 05000 10 0000 150 | Артык түләнгән яки артык алынган салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр суммаларын, шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган өчен процентлар суммалары һәм артык алынган суммаларга процентларны кире кайтаруны (исәпкә алуны) гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларыннан (авыл җирлекләре бюджетларына) күчерелгән акчалар. |
| 500 | 2 08 10000 10 0000 150 | Түләтүне гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларыннан (авыл җирлекләре бюджетларына) күчерүләр |
| 500 | 2 18 05010 10 0000 150 | Бюджет учреждениеләре тарафыннан узган еллардагы калган субсидияләрне кире кайтарудан авыл җирлекләре бюджеты кереме |
| 500 | 2 18 05020 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларының узган еллардагы субсидия калдыкларын автоном учреждениеләр тарафыннан кире кайтарудан керемнәре |
| 500 | 2 18 05030 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларының узган еллардагы субсидия калдыкларын башка оешмалар тарафыннан кире кайтарудан керемнәре |
| 500 | 2 18 60010 10 0000 150 | Максатчан билгеләнеше булган узган еллардагы субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертларның калдыкларын муниципаль районнар бюджетларыннан кире кайтарудан авыл җирлекләре бюджетлары керемнәре |
| 500 | 2 19 45160 10 0000 150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән |

| | | |
|---|---|---|
| | | өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен тапшырыла торган башка бюджетара трансфертларның калган өлешен авыл җирлекләре бюджетларыннан кире кайтару |
| 500 | 2 19 60010 10 0000 150 | Максатчан билгеләнеше булган узган еллардагы субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның башка калдыкларын авыл җирлекләре бюджетларыннан кире кайтару |
| **Барлык администраторларга беркетелә торган керемнәр** | | |
| 000 | 1 16 10123 01 0051 140 | 2019 елда гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиешле 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны түләү исәбенә керүче акчалата түләтүдән (штрафлардан) керемнәр (муниципаль районнар бюджетлары керемнәре, муниципаль юл фондын формалаштыруга җибәрелә торган керемнәрдән тыш, шулай ук муниципаль берәмлекнең финанс органы тарафыннан бурычларны аерым исәпкә алу турында карар кабул ителгән очракта бүтән түләүләрдән тыш) |
| 000 | 1 16 11050 01 0000 140 | Әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча түләүләр, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны (аеруча саклаулы табигать территорияләрендә әйләнә-тирә мохиткә салынган зыяннан, шулай ук су объектларына китерелгән зыяннан тыш) ирекле каплаганда түләнә торган түләүләр, алар муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиеш |